# КАРАР

**03 декабрь, 2024 ел** **№2**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлеге Филипповка поселогында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 03 декабрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Оштырма-Юмья авыл җирлеге Филипповка поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суыртү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (Филипповка поселогында су белән тәэмин итү системаларын, су саклау зоналарын, су суыртү манараларын, артезиан скважиналарын һәм башка инженерлык челтәрләрен проектлау, төзү, ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, бетон боҗралар, капкачлар һәм люклар, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, эш өчен шартнамә буенча түләү, проект-смета документларын эшләү

һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре)

- коеларны ясау, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү; коеларны ремонтлау һәм коелар территориясен төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Филипповка поселогында савытлар, янгын сүндерү рукавларын, стволларны, күчермәләрне, колонкаларны, мотопомпаны карап тоту, сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка эш төрләре);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Филипповка поселогының урам юл челтәрен карап тоту, кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, төзекләндерү; трактор һәм чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, юл челтәрен карап тоту буенча башка эш төрләре) (Филипповка поселогы урамнарында юлларга вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, сүүткәргеч торбалар урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү; юлларны карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:
2023 елның 03 декабренә торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны – 68 кеше.

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 56 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 37 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 37 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Вильмон поселогында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Оштырма-Юмья авыл җирлеге Филипповка поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия

Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- коеларны ясау, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү; коеларны ремонтлау һәм коелар территориясен төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Филипповка поселогында савытлар, янгын сүндерү рукавларын, стволларны, күчермәләрне, колонкаларны, мотопомпаны карап тоту, сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка эш төрләре);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Филипповка поселогының урам юл челтәрен карап тоту, кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, төзекләндерү; трактор һәм чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, юл челтәрен карап тоту буенча башка эш төрләре) (Филипповка поселогы урамнарында юлларга вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, сууткәргеч торбалар урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү; юлларны карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

2. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Оштырма-Юмья авыл җирлеге
башлыгы: С.В. Тимофеев